КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1448

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 гыйнвар, 32 нче, 2018 ел, 20 июнь, 501 нче, 2020 ел, 21 февраль, 124 нче, 2020 ел, 10 апрель, 268 нче, 2020 ел, 25 июнь, 527 нче, 2021 ел, 21 июнь, 491 нче, 2022 ел, 15 июль, 682 нче, 2023 ел, 07 апрель, 428 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында нигезлмәгә, 2.3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнүче һәм вазыйфадан азат ителүче, аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеген раслау турында «2017 ел, 6 ноябрь, 847 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башкарма органнарында» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнүче һәм вазыйфадан азат ителүче, аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлегендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 март, 196 нчы, 2019 ел, 29 апрель, 353 нче, 2019 ел, 8 ноябрь, 1026 нчы, 2020 ел, 23 сентябрь, 862 нче, 2023 ел, 17 апрель, 474 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең түбәндәге башкарма органнары» сүзләрен «түбәндәге республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Р.Т.Борһановны, А.А.Кәримовны, Л.Р.Сафинны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимировичны | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Хәдиуллин Илсур Гәрәй улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын |
| Хәнифов Фәрит Мөдәрис улын | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрын |

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары турында» 2005 ел, 30 март, 159 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тәэмин итү чаралары турында» 2010 ел, 30 март, 200 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин